**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 май № 368

г. Казань

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 5 сентябрь, 636 нчы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\368.doc

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында
кече һәм урта эшмәкәрлек
субъектларына булышлык күрсәтү өчен
Татарстан Республикасы Хөкүмәте
грантларын бирү тәртибенә 1 нче
кушымта

Форма

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары проектлары конкурсында катнашуга
гариза

______________________________________________________________________,
(гариза бирүче исеме)

ИНН____________________, КПП________________, ОГРН_____________

Тәкъдим ителгән проект исеме: ______________________________
______________________________________________________________________.

Проектның эчтәлеге, вакытларын һәм бәясен нигезләү теркәлгән документларда китерелә. Тапшырылган мәгълүматның дөреслегенә ышандырам.

Гариза бирүче
җитәкчесе

_____________ (имза)    ____________________ (имзаның аңлатмасы)

М.У.

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында
кече һәм урта эшмәкәрлек
субъектларына булышлык күрсәтү өчен
Татарстан Республикасы Хөкүмәте
грантларын бирү тәртибенә 2 нче
кушымта

Форма

**Гариза бирүче анкетасы**

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Гариза бирүче мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Проект исеме | |
| 2. | Проектның максаты һәм бурычлары | |
| 3. | Соралган грант суммасы, мең сум | |
| 4. | Көтелгән нәтиҗәләр | |
| 5. | Гариза бирүченең тулы исеме | |
| 6. | ИНН | |
| 7. | КПП | |
| 8. | ОГРН | |
| 9. | ОКПО | |
| 10. | ОКВЭД буенча эшчәнлек төре | |
| 11. | Юридик адресы | |
| 12. | Гамәлдәге адресы | |
| 13. | Дәүләт теркәвенә алыну датасы | |
| 14. | Гариза бирүче җитәкчесе (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, элемтә реквизитлары) | |
| 15. | Баш хисапчы (фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә реквизитлары) | |
| 16. | Проект җитәкчесе (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, элемтә реквизитлары) | |
| 17. | Җаваплы башкаручы (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, элемтә реквизитлары) | |
| 18. | E-mail | |
| 19. | Проектның максатчан аудиториясе һәм катнашучылары географиясе, саны | |
| 20. | Проектны тормышка ашыру вакытлары | |

Гариза бирүче
җитәкчесе

__________________ __________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

М.У.

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында
кече һәм урта эшмәкәрлек
субъектларына булышлык күрсәтү өчен
Татарстан Республикасы Хөкүмәте
грантларын бирү тәртибенә 3 нче
кушымта

Форма

**Проектның паспорты**

______________________________________________________________
(проект исеме)

**1. Проектның һәм аның максатларының кыскача тасвирламасы** (150 сүздән артык түгел, проектның яңалыгы, нәтиҗәләрен төгәл куллану, киләчәктә файдалану һәм башкалар).

**2. Проектны тормышка ашырудан планлаштырылган нәтиҗә.**

**3. Җитештерүне һәм продукцияне сертификацияләү** (сертификатлар булу, җитештерүне һәм продукцияне сертификацияләү буенча Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләр булу, җитештерүне һәм продукцияне сертификацияләү буенча планнар).

**4. Проектны тормышка ашыру өчен төп үз акчасы булу** (машиналар һәм җиһазлар, биналар һәм корылмалар, җир кишәрлекләре һ.б.).

**5. Проектны тормышка ашыру өчен техник мөмкинлекләр булу** (җитештерүне оештыру өчен кирәкле техник шартлар булу – техник ялгаулар, таләп ителгән куәт булу һ.б.).

**6. Проектны тормышка ашыру урыны.**

**7. Проектны тормышка ашыру вакыты, айлар.**

**8. Проектның тулы бәясе, мең сум.**

**9. Таләп ителгән финанслау, мең сум.**

**10. Күздә тотылган финанслау чыганаклары.**

**11. Бу проект башка чыганаклардан финансланганмы** (финансланган булса, кем тарафыннан һәм күпме күләмдә).

**12. Проектның җитәкчесе** (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, имза).

Гариза бирүче җитәкчесе ____________ (имза) ____________ (имзаның аңлатмасы)

М.У.

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

**Проектны тормышка ашыруның календарь планы**

_______________________________________________

(проект исеме)

| Т/с | Проект буенча эшләр һәм аларның төп этаплары исеме | Эшләрне башкару вакыты, айлар | Эшләр этабының исәпләнгән бәясе, мең | Хисаплылык формасы һәм төре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |

Гариза бирүче житәкчесе ____________________ ____________________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

М.У.

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә 5 нче кушымта

Форма

**Проект буенча чыгымнар сметасы (җиһазларга һәм материалларга)**

______________________________________________

(проект исеме)

| Эшләр башкаруга тотылган акча | Суммасы, сум | Эшләр этаплары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 |
| 1. Сатып алырга планлаштырылган җиһаз | | | | |
| 1.1. | | | | |
| 1.2. | | | | |
| 1.3. | | | | |
| 2. Материаллар һәм тупланмалар | | | | |
| 1.1. | | | | |
| 1.2. | | | | |
| 1.3. | | | | |
| Алардан:<br>үз акчасы | | | | |
| грант акчасы | | | | |
| башка акчалар (кредитлар, заемнар һ.б.) | | | | |
| 3. Булган җиһазлар (җитештерүдә кулланыла торган) | | | | |

Гариза бирүче җитәкчесе ________________ ________________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

М.У.

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә 6 нчы кушымта

Форма

## Грантны максатчан файдалану турында хисап

____________________________________________________________

(проект исеме)

| Акчаны (грантны) файдалану юнәлеше | Чыгымнарны функциональ классификацияләү коды | | | | Чыгымнарны икътисадый классификацияләү коды | Ел башыннан кергән акча | Ел башыннан тотылган акча |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүлек | бүлекчә | максатчан статья | чыгым төре | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |

Гариза бирүче җитәкчесе

________________ (имза)

____________________ (имзаның аңлатмасы)

М.У.

F:\KARAR\2015\368-1.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 25 май, 368 нче карары
белән расланды

**Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү**
**ТӘРТИБЕ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон), «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 ел, 12 гыйнвар, 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 ел, 21 гыйнвар, 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында эшләнде.

1.2. Бу Тәртип максатларында түбәндәге терминнар файдаланыла:

халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (алга таба – грант) – Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына халык сәнгать һөнәрләре тармагында товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә финанс ярдәме күрсәтү максатларында бирелә торган субсидия;

эшмәкәрлек субъектлары - халык сәнгать һөнәрләре тармагында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары;

конкурс комиссиясе – грантлар бирү өчен халык сәнгать һөнәрләре тармагында эшмәкәрлек субъектлары проектларын (алга таба – проектлар) сайлап алу комиссиясе.

1.3. Бу Тәртип нигезендә грантлар бирү халык сәнгать һөнәрләре осталарының һәм оешмаларының иҗади потенциалын тормышка ашыру, халык сәнгать һөнәрләре әйберләрен җитештерү һәм реализацияләү өчен шартлар тәэмин итү, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның төрле яшьтәге категорияләре өчен халык сәнгать һөнәрләре тәҗрибәсен һәм традицияләрен тапшыру буенча халык сәнгать һөнәрләре осталары эшчәнлеген оештыру өчен

мөмкинлекләр тудыру максатыннан чыгып, проектларны сайлап алу конкурсын үткәрү нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Сайлап алу конкурсына тапшырылган халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре (үрнәкләр) «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 ел, 6 гыйнвар, 7-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы һәм Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Алар нигезендә эшләнмәләрне халык сәнәгать һөнәрләре эшләнмәләре итеп карау гамәлгә ашырылган халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү төрләре һәм аларның төркемнәре исемлеге турында» 2009 ел, 15 апрель, 274 нче боерыгы белән расланган халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү төрләре һәм аларның төркемнәре исемлеге таләпләренә ярашырга тиеш.

1.5. Дәүләт ярдәме проектларны тормышка ашыруны максатчан финанслау өчен эшмәкәрлек субъектларына һәркайсы иң күбе 300 000 (өч йөз мең) сум торган грантлар бирү юлы белән күрсәтелә.

1.6. Сайлап алу конкурсын оештыруны, шулай ук грантлар алучылар белән килешүләр төзүне Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы гамәлгә ашыра.

## 2. Сайлап алу конкурсында катнашу хокукы

2.1. Эшмәкәрлек субъекты түбәндәге очракларда сайлап алу конкурсында катнаша ала:

209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап биргәндә;

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгәндә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда;

эшмәкәрлек субъектының проектны тормышка ашыруга тота торган үз акчасы проектның тулы кыйммәтеннән кимендә 15 процент күләмендә булганда.

## 3. Конкурста сайлап алу критерийлары

3.1. Проектларны конкурста сайлап алу (алга таба – конкурс) түбәндәге сайлап алу критерийлары нигезендә үткәрелә:

а) тапшырылган халык сәнәгать һөнәрләре эшләнмәләренең игълан ителгән конкурс шартларына туры килүе;

б) эшмәкәрлек субъектының матди-техник һәм кадрлар ресурслары булу;

в) проектның иҗади үзенчәлеге, соңгы нәтиҗәнең сәнгати кыйммәте һәм актуальлеге, аның гамәли кулланууда максатчанлыгы;

г) халык сәнәгать һөнәрләрен үстерүне тәэмин итү, халык сәнәгать һөнәрләренә халыкны тарту өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче төрле яшь категорияләрендәге гражданнар өчен халык сәнәгать һөнәрләрен тәҗрибәсен һәм гореф-гадәтләрен тапшыру буенча халык сәнәгать һөнәрләре осталары эшчәнлеген оештыру;

д) тәкъдим ителгән халык сәнәгать һөнәрләре эшләнмәләрен халык сәнәгать һөнәрләре гадәти көнкүрештә кулланылган урыннарда әзерләү;

е) проектның икътисади максатчанлыгы һәм аның нәтиҗәлелеге.

## 4. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

4.1. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, коммерциячел булмаган оешмалар, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан 9 кеше составында Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән төзелә.

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынучы затлар (шул исәптән конкурста катнашуга гаризалар биргән йә әлеге гаризаларны тапшырган оешмалар штатында торучы) йә конкурста катнашучылар йогынты ясый ала торган затлар конкурс комиссиясе әгъзалары була алмый.

4.2. Конкурс комиссиясе эше аның утырышларында гамәлгә ашырыла. Утырыш, әгәр дә анда конкурс комиссиясе әгъзалары гомуми санынннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы булып санала.

4.3. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән тавышларның гади күпчелеге буенча кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

4.4. Конкурс комиссиясе рәисе оештыру-техник эшчәнлекне координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документларны алып бару өчен җаваплы сәркатип билгели.

4.5. Конкурс комиссиясенең җаваплы сәркатибе түбәндәге функцияләрне башкара:

конкурска гаризалар кабул итә һәм аларны кергән тәртиптә терки;

конкурс комиссиясе утырышында тикшерү өчен материаллар әзерли һәм аларны саклауны оештыра;

конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә.

Конкурс комиссиясенең җаваплы сәркатибе аның составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

4.6. Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен аның рәисе утырыш үткәрелгән көннән алып 3 көн эчендә раслый, алар расланган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

## 5. Конкурсны үткәрү тәртибе

5.1. Конкурс үткәрү турындагы игълан гаризалар кабул итү тәмамланганга кадәр 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарыла һәм конкурс үткәрү вакыты, урыны һәм тәртибе, конкурска гаризалар кабул итү башлану һәм тәмамлану вакыты хакында белешмәләрне үз эченә ала.

5.2. Конкурска гаризалар кабул итү вакыты конкурс үткәрү турында игълан бастырып чыгарылган көннән исәпләнелә. Конкурста катнашу өчен бер генә гариза да кертелмәгән очракта, конкурс үткәрелмәде дип санала.

5.3. Конкурста катнашу өчен эшмәкәрлек субъекты Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына составында түбәндәге документлар булган гариза кертә:

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча конкурста катнашуга гариза;

гариза бирүченең конкурска гариза тапшырган вакытка аның шундый ук дәүләт финанс ярдәмен алучы булмавы турындагы хәбәрнамәсе;

составына түбәндәгеләр кергән проект планы:

бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча конкурста катнашуга гариза бирүче анкетасы;

бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча проект паспорты;

бу Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча проектны тормышка ашыру буенча календарь планы;

бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча проектның чыгымнар сметасы.

5.4. Тапшырыла торган барлык документлар формаларының бөтен пунктлары да тутырылырга, һәм ул моңа вәкаләт бирелгән затның имзасы һәм гариза бирүченең мөһере белән таныкланырга тиеш. Конкурска гаризаның барлык битләре тегелергә һәм аларга тәртип саны куелырга тиеш.

5.5. Конкурска гариза Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына ябыштырылган конвертта язма рәвештә кертелә. Конвертта гариза бирүченең исеме һәм адресы, проектның исеме күрсәтелә.

5.6. Конкурска гариза составында кирәкле документлар булмау, документларда дөрес булмаган мәгълүматлар йә бу Тәртипнең 2.1 нче пунктына туры килми торган мәгълүматлар булу гариза бирүчене конкурста катнаштырмау өчен нигез булып тора.

5.7. Гариза бирүченең 209-ФЗ номерлы Федераль закон һәм бу Тәртип таләпләренә туры килү-килмәве түбәндәге документлардагы мәгълүмат нигезендә билгеләнә:

а) эшмәкәрлек субъектын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык;

б) эшмәкәрлек субъектын салым органында исәпкә кую турындагы таныклык;

в) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә;

г) оешма мөһере һәм җитәкче имзасы белән расланган устав күчермәләре (юридик затлар өчен);

д) эшмәкәрлек субъектының соңгы хисап датасына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары булмау турында салым органыннан белешмә кәгазе (агымдагы хисап чорында теркәлгәннәрдән тыш);

е) оешма һәм халык сәнәгать һөнәрләре эшләнмәләрен ясау гореф-гадәтләре турында кыскача тарихи белешмә;

ж) тиешле материалдан ясалган эшләнмәләр үрнәкләре.

Гариза бирүче әлеге Тәртипнең 5.7 пунктындагы «а», «б», «в», «д» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органында соратып ала.

Эшмәкәрлек субъекты Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына әлеге документларның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен кертергә хокуклы.

5.8. Бу Тәртип һәм конкурска гариза составына керә торган документлар формалары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.mincult.tatar.ru) урнаштырыла.

5.9. Конкурска гариза әзерләү буенча барлык чыгымнар гариза бирүче тарафыннан тотыла.

5.10. Конкурска гаризалар Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан алар кергән тәртиптә 3 көн эчендә теркәлә.

5.11. Кабул итү вакытлары үткәннән соң алынган конкурска гаризалар конкурста катнашуга кертелми.

5.12. Бу Тәртип нигезендә каралган конкурска гаризалар Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында 3 (өч) ел саклана.

5.13. Конкурска гаризалар салынган конвертларны ачу һәм конкурста катнашучылар исемлеген игълан итү конкурс комиссиясе утырышында конкурска гаризалар кабул итеп бетергән көннән 3 көн эчендә үткәрелә. Гариза бирүчеләр вәкилләре конкурс комиссиясенең конвертларны ачу утырышында катнашырга хокуклы. Конкурста катнашу өчен кергән барлык гаризалар да конвертлар ачу процедурасында катнаша.

5.14. Конкурста катнашучылар исемлеген формалаштыру конкурс комиссиясенең конвертларны ачу утырышы беркетмәсендә чагыла, анда конкурста катнашуга кергән гаризалар саны, конкурста катнашучылар һәм проектлар исеме күрсәтелә. Конкурс комиссиясенең конвертларны ачу утырышы беркетмәсе бу Тәртипнең 4.6 нчы пункты нигезендә рәсмиләштерелә һәм раслана.

5.15. Конкурс комиссиясе конвертларны ачу утырышы үткәрелгән көннән соң 14 көн эчендә конкурсны үткәрә һәм әлеге Тәртипнең 3 бүлегендә билгеләнгән критерияләр нигезендә 10 баллы шкала (0 дан 10 га кадәр) буенча тапшырылган проектларны бәяли.

5.16. Һәр критерия буенча баллар суммасы нигезендә конкурс комиссиясе конкурста катнашучылар рейтингын эшли.

5.17. Грантлар күләмнәре соралган суммага, рейтингта торткан урынына һәм тапшырылган проект буенча чыгымнар сметасына ярашлы проектны тормышка ашыруга күздә тотылган, әмма әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән суммадан артмаган акчага бәйле рәвештә дифференциацияләнәләр.

5.18. Конкурс комиссиясе 2 көн эчендә рейтинг нигезендә, бирелә торган грант күләмен күрсәтеп, җиңүчеләр исемлеген төзи. Бирелә торган грант күләме

күрсәтелгән җиңүчеләр исемле Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан 3 эш көне эчендә раслана.

5.19. Конкурс җиңүчеләре исемлеге расланган көненнән соң эш көннәрендә исәпләнелгән 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

## 6. Грантлар алучыларга акча түләү тәртибе

6.1. Грантларны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы раслый торган форма буенча грант бирү турындагы килешү нигезендә акчаны грантлар алучыларның хисап исәпләренә күчерү юлы белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы бирә.

6.2. Грант бирү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грант алучы белән төзегән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла, анда түбәндәгеләр карала:

а) финанс тәэминаты һәм (яки) аларны каплау грант исәбенә башкарылучы проектларны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнар төрләре;

б) грантны күчерү тәртибе;

в) грант күләме;

г) килешүдә билгеләнгән күрсәткечләр нигезендә грантны файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү;

д) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы үткәргән тикшерүләр йомгаклары буенча грантны максатчан булмаган файдалану һәм әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән шартларны бозу фактлары билгеле булган очракта грант алучы файдаланган суммаларны кире кайтару тәртибе;

е) хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калган өлешләрен Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтару тәртибе;

ж) грантны файдалану турында хисап бирү тәртибе һәм вакытлары;

з) грант алучының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан грант алучылар тарафыннан аларның килешүдә билгеләнгән шартларын, максатларын һәм тәртибен бозмавына тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы.

6.3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җиңүчеләр исемлеге урнаштырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 30 көн эчендә грант алучы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән грант бирү турында килешү төзергә тиеш.

## 7. Гранттан файдалануны тикшерүдә тоту

7.1. Грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, алардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри тикшерүләр үткәрү юлы белән Татарстан Республикасының

Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашыра.

7.2. Грант түләү өчен бүлеп бирелгән, хисап финанс елында файдаланылмый калган акча грант бирү турындагы килешүдә күздә тотылган тәртиптә һәм очракларда Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

7.3. Грант алучы грант бирү турында килешүдә билгеләнгән вакытларга ярашлы рәвештә Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына бу Тәртипкә теркәлгән 6 нчы кушымтада күрсәтелгән форма буенча гранттан максатчан файдалану турында өч нөсхәдә хисап һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы Сәнгать-эксперт советының эшләнмәнең халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә каравын раслаучы бәяләмәсен кертә.

7.4. Грантлар түбәндәге очракларда акчаны файдалану турында хисап тапшырылу мизгеленнән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемено кайтарылырга тиеш:

грантлар бирү шартлары үтәлмәгәндә;

грантлар максатчан файдаланылмаганда.

Күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан тартып алынырга тиеш.

7.5. Дәүләт ярдәме тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме кысаларында эшмәкәрлек субъектларына грантлар бирү юлы белән күрсәтелә.

F:\KARAR\2015\368-2.docx